ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«11» июнь 2020 ел № 443

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 598 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 598 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына (06.12.2019 ел, №1080, 27.04.2020 ел, №315 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

VII бүлектә:

1 пунктның бишенче абзацында «сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«7. Аерым белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен мәгариф хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр бирелә»;

7.1 пунктында:

беренче абзацта «сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 пунктның беренче абзацында «сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 нче таблицаның атамасында "сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән" сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтаның "Кызыксындыру түләүләре билгеләнә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегенең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | "Мәгариф отличнигы" билгесе; |

әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

III бүлекнең 2 пунктында «беренче-икенче төркем белән» сүзләрен «бер-ике төркем белән» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлектәге 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

"2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар өчен ике төрле яшь төркемнәрендә, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч төрле яшь төркемнәрендә хезмәт күрсәткән педагогик хезмәткәрләрнең һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары структур бүлекчәләре җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары үз көченә кергәнче түләнә торган күләмдә башкарыла.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның "Кызыксындыру түләүләре билгеләнә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегенең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | "Мәгариф отличнигы" билгесе; |

әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә кушымтаның 1 нче таблицасында "Кызыксындыру түләүләре билгеләнә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.7 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.7. | "Мәгариф отличнигы" билгесе; |

әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

V бүлектә 2 пунктның бишенче абзацында "300" санын "550" санына алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасында "Кызыксындыру түләүләре билгеләнә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегенең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | "Мәгариф отличнигы" билгесе; |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Мөхәрәмовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин